КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 октябрь

г.Казань

№ 923

Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төбәк яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына кертү критерийларын раслау турында

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төбәк яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына кертү критерийларын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына кертү критерийларын раслау турында» 2008 ел, 22 сентябрь, 692 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына кертү критерийларын раслау турында» 2008 ел, 22 сентябрь, 692 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 19 ноябрь, 918 нче карары.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 25 октябрь, 923 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы
автомобиль юлларын төбәк яки муниципальара әһәмияттәге
гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына кертү
критерийлары

Татарстан Республикасында төбәк яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына (алга таба – Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары) түбәндәге автомобиль юллары (федераль әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан тыш) керә:

Татарстан Республикасы башкаласы – Казан шәһәрен Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре белән тоташтыра торган;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләрен үзара тоташтыра торган;

Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы белән уртак чиге булган Россия Федерациясе субъектлары белән элемтәсен тәэмин итә торган;

Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын үзара, федераль әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын үзара һәм федераль әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары белән тоташтыра торган;

Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы әйләнеп уза торган автомобиль юллары булмаган һәм Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының состав өлеше булган торак пунктлар аша уза торган;

Татарстан Республикасының торак пунктларын Татарстан Республикасында федераль әһәмияттәге яисә төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары белән IV техник категориядән түбән булмаган һәм эксплуатация торышына карата норматив таләпләргә туры килә торган асфальт-бетон яки цемент-бетон капламага ия торак пунктлар чикләренә кадәр тоташтыра торган;

Татарстан Республикасында федераль әһәмияттәге яки төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан IV техник категориядән түбән булмаган һәм эксплуатация торышына карата норматив таләпләргә туры килә торган асфальт-бетон яки цемент-бетон капламага ия торак пунктлар чикләреннән читтә урнашкан Татарстан Республикасы милкендәге объектларга (энергетика системалары; транспорт (тимер юл, су, һава транспорты); Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең өстенлекле юнәлешләре нигезендә урнаштырылган яисә

төзергә планлаштырыла торган капиталь төзелеш; агросәнәгать комплексы объектларына) килә торган юллар булып торган.

---